Гаилә ул - тормышнын зур бvләге. Аны булдыра һәм яшәтә белергә һәркемгә дә бирелмәгән. Әмма хормәткә лаек гаиләләр байтак.

Гаиләдә ир белән хатыннын бер-берсенә мәхәббәтен, тугрылыгын, жылы монәсә-бәтен, гаилә бәхетен, vзара килешеп, тату яшәвен кvрv бик тә кvркәм кvренеш. Якыннарына, авылдашларына тормышта унган-булган гаилә гомер буе кулга-кул тотынып баруларын һәм әйләнә-тирәдәгеләргә vр-нәк булулары белән кадерле дә. Шундый гаиләләрнен берсе Ләмберә районы Татар Тавла авылында бергә-бергә тату гомер итvче, яшь гаиләләргә vрнәк булып торучы Мясоутовлар гаиләсе бар. Ярты гасырдан артык бергә дус-тату гомер итә алар. Барлык гаиләләргә дә алар кебек бер-берсен хормәт итеп, тормышнын кадерен белеп, гvзәллеген, тәмен тоеп, бәхетле булып яшәргә насыйп булсын.

Әйтеп китергә кирәк, Татар Тавла авылында хезмәт соючән, тырыш, эшле һәм ашлы халык яши. Мәдәниятларын, туган татар телләрен, диннәрен дә яратып буыннан-буынга бvләк итеп торалар. Шуна да сонгы елларда бу авыл vсеп китте: яна йортлар тозелде, балалар туды...

Язма геройларыбыз Исхак Сәяф улы белән Роза Исмаил кызы Мясоутовлар туып-vскән Тавла авылында 1969 елнын мартында, гомер-гомергә яшәгән гадәт буенча, горләтеп туйларын vткәрәләр һәм менә 53 ел инде бергә-бергә шунда матур гомер итәләр. Мул тормыш нигезендә тырышлык. Авыл кешесе шуны тоеп яши, ризык бәрәкәтен, яшәv шатлыгын хәләл хезмәтендә кvрә. Исхак Сәяф улынын да эш стажы - 45 ел. Ул туган Татар Тавла кырларында, ике авыл кырлары бергә кушылгач, кvрше Аксёново авылында комбайнчы, тракторчы булып озак еллар тырышып хезмәт итә. Роза Исмаил кызынын да эш стажы 35 ел: ул туган авылы сыерларын савучы булып эшләгәннән сон, шәһәрдә авыр тозvче хезмәтен vти. Авыл жирендә хезмәтсез булмый шул. Биредә тырышлык бар жирдә чагыла. Хезмәттән кайткач, йорт тирәсе эшләрен башкарасы бар. Мал-туар, бакча һәм башка бик кvп торле-торле эшләрне кояш батканчы башкарасы бар; балаларны тәрбияләп vстерәсе бар. Хезмәт, хужалыктагы эш белән бергә, ирле-хатынлы Мясоутовлар дvрт бала тәрбияләп vстергәннәр, ә балалары онык һәм оныкчыклар бvләк иткәннәр; хәзер аларнын 9 онык-лары һәм 2 оныкчыклары бар. Бvген алар икесе дә лаеклы ялда. Балаларына шокер кылып, оныкларын яратып, оныкчыкларын иркәләп, ярдәмләшеп яшиләр алар. Бәйрәмнәрдә йорт тутырып, бергәләшеп әниләре пешергән алка-кабартмалар, пәрәмәчләр, кош теле-бәлешләр белән бергә чәй эчәләр, тормыш хәлләре белән уртаклашалар.

Н.ХӘЛИЛ